

Ельники туган якны ойрәнv музеенда алты татар авылы һәм Ельники районы тарихы буенча китап остендә эш тәмамлана. Китап архив документларына нигезләнгән; анда укучыларнын тикшеренv эшләре һәм олкәннәрнен истәлекләре кертелгән. Авторларнын берсе безгә билгеле булган Акчеево авылынын хормәтле укытучысы Румия Камиль кызы Шехмаметьева.

Материалларны жыю барышында авторлар берничә тапкыр татар авылларында туып-vскән, Россиянен торле тобәкләрендә яшәvче халыкнын буыннарына китап язуда катнашу vтенече белән морәжәгать иткәннәр. Кvпләре жавап кайтарган. Алар жибәргән материаллар китапка кертелгән; алар аны мәгънәле һәм кызыклы итә.

Ноябрь аенда яна материаллар алганнар. Бvген Мәскәv олкәсендә яшәvче Кадышево авылында туган Камиль Хәлим улы Богданов vзенен истәлекләрен жибәргән. 11 елдан артык ул «Сельхозтехника» район берләшмәсе идарәчесе вазыйфасын башкаручы, аннары – идарәчесе (управляющий) булып эшләгән. Ильдар Янбухтин (Мәскәv олкәсе) һәм Эльвера Косова (Мәскәv) да кызыклы материаллар жибәргәннәр. Алар Камалетдин Раджаб улы Шехмаметьев нәселеннән (1870 елда туган) Лобановка авылыннан.

Уртак тырышлык белән торле чорларнын кvп фотосурәтләре жыелган, алар безгә кvптән vткән заманнарга кvчәргә, эшчәнлекнен торле олкә-ләрендә хезмәт куйган кешеләрнен йозләрен кvрергә момкинлек бирә. Солдатлар, тракторчылар, шәфкать туташлары, укытучылар – алар барысы да жәмгыять файдасына намуслы хезмәт итvчеләр.

Китап 2023 ел башында подписка буенча якынча 1000 битле иттереп бастырылачак.